СОВЕТ МАЛОЛЫЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КЕЧЕ ЛЫЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

« 28» октябрь 2022 ел

№57

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым җыю һәм файдалану тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы № 131-ФЗ Федераль законның 56 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Кече Лызи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге территориясендә үзара салым җыю һәм гражданнарның үзара салымы тәртибе турындагы Кече Лызи авыл җирлеге Советының 11.04.2014 елгы № 112 нче карары белән расланган (06.02.2015 ел, №168, 14.11.2019 ел, №135 редакциясендә) нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 5.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

"Җирле референдумда кабул ителгән карар нәтиҗәләрен игълан иткәннән соң, 18 яшькә җиткән барлык гражданнарга да үзара салым акчаларын түләүне өч ай эчендә башкарырга, яшәү урыны җирлек чикләрендә булган,җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләргә карамастан, үзара салым суммасының 90 проценты күләмендә ташлама билгеләнгән: 1нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәкләрдән, сәләтсез гражданнардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, өлкән яшьтәге ялгыз пенсионерлардан, үз – үзләренә хезмәт күрсәтә алмаган гражданнардан, балигъ булмаган балаларны тәрбияләүче тулы булмаган куп балалы гаилә әгъзаларыннан, балигъ булмаган балаларны тәрбияләүче ялгыз аналардан, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларыннан; үзара салым суммасыныц 50% күләмендә ташлама билгеләнгән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, җирлек башкарма комитетының хәбәрнамәсе нигезендә җирлек башкарма комитетының банк реквизитларын, шулай ук түләү тәртибе турындагы мәгълүматны үз эченә ала.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга, Татарстан

Республикасы Балтач муниципаль районының http://baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга һәм Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге территориясендә урнаштырылган мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасы, Балтач районы, Кече Лызи авылы, Узэк урамы 2 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында халыкка җиткергән (бастырып чыгарган) һәм Балтач муниципаль районының http://baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырган мизгелдән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл Советы Рәисе,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы А.С.Исмагилов